ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

# БОЕРЫК

20.07.2020 № 143-од

Казан шәһәре

Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында

«Россия Федерациясендә архив эше турында» 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшереп тору чараларын үткәрүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карары, «Татарстан Республикасында архив эше турында» 2017 елның 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 елның 9 августындагы 541 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп торуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруның административ регламентын раслау хакында» 2017 елның 11 гыйнварындагы 004-од номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының 2017 елның 14 мартындагы 024-од номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору

чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында нигезләмәне 2019 елның 16 декабрендәге 439-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Түбәндәгеләрне расларга:

1.1. Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә).

1.2. Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү критерийларын.

1.3. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәргәндә кирәкле экспертизалар төрләре исемлеген.

1.4. Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә җәлеп ителүче аттестацияләнгән экспертлар реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләрен.

2. Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясен төзергә.

3. Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында» 2017 елның 14 мартындагы 024-од номерлы;

«Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетының «Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында» 2017 елның 14 мартындагы 024-од номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 августындагы 149-од номерлы;

4. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәсми сайтына урнаштырырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис Г. З. Габдрахманова

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының 2020 елның 07 июлендәге 143-од номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## 1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (алга таба – Дәүләт комитеты) тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе (алга таба – Аттестация комиссиясе) «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшереп тору чараларын үткәрүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү өчен төзелә.

2. Аттестация комиссиясе үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына һәм боерыкларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, архив эше өлкәсенә караган норматив һәм методик документларга, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Әлеге Нигезләмәдә Аттестация комиссиясенең эш тәртибе һәм составы, квалификация имтиханын үткәрү тәртибе билгеләнә.

4. Аттестация комиссиясе эшчәнлегенең төп принципларына компетентлык, объективлык, ачыклык, бәйсезлек, һөнәри этика нормаларын үтәү керә.

## 2 бүлек. Аттестация комиссиясе структурасы

6. Аттестация комиссиясе архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору буенча чаралар үткәрүгә Дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче эксперт аттестациясе алуга дәгъва кылучы гражданнар өчен квалификация имтиханын уздыру максатларында даими нигездә төзелде.

7. Аттестация комиссиясе Дәүләт комитеты хезмәткәрләреннән төзелә торган коллегиаль орган булып тора.

Аттестация комиссиясе составына Дәүләт комитеты рәисе, Дәүләт комитеты рәисе урынбасары һәм Дәүләт комитеты рәисе тарафыннан вәкаләт бирелгән дәүләт граждан хезмәткәрләре (шул исәптән дәүләт контроле секторыннан) кертелә. Составка Дәүләт комитеты хезмәткәрләре так санда кертелә.

8. Аттестация комиссиясенең персональ составы Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

9. Аттестация комиссиясе утырышында аның әгъзаларының кимендә өчтән ике өлеше катнашса, ул хокуклы санала.

10. Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе – Аттестация комиссиясе рәисе, Архив эше буенча Дәүләт комитеты рәисе урынбасары – Аттестация комиссиясе рәисе урынбасары була, Аттестация комиссиясе үз составыннан секретарьны бер елга сайлап куя. Аттестация комиссиясе секретаре итеп сайланган хезмәткәр эштән киткән очракта, Аттестация комиссиясе секретарьны яңартылган составтан сайлап куя.

Аттестация комиссиясе рәисе:

10.1. Аттестация комиссиясе эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

10.2. Аттестация комиссиясенең әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән эш тәртибе саклануны тәэмин итә;

10.3. Аттестация комиссиясе утырышларын оештыра һәм үткәрә;

10.4. Аттестация комиссиясе әгъзалары һәм секретаре арасында вазыйфаларны бүлә;

10.5. Аттестация комиссиясе утырышында тикшерелә торган мәсьәләләрне карау тәртибен билгели;

10.6. Аттестация комиссиясе кабул иткән карарларның үтәлешен үз компетенциясе чикләрендә тикшереп тора;

10.7. законнарда һәм әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра;

10.8. Аттестация комиссиясе рәисе булмаганда, аның функцияләрен Аттестация комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

11. Аттестация комиссиясе секретаре:

11.1.Аттестация комиссиясенең эш башкаруын алып бара;

11.2. Аттестация комиссиясенә керүче документларны кабул итә, документларны рәсмиләштерүнең дөреслеген тикшерә, аларны Аттестация комиссиясе утырышында карау өчен әзерли;

11.3. Аттестация комиссиясе әгъзаларына аларның функцияләренә караган барлык мәсьәләләр буенча мәгълүмат бирә, Аттестация комиссиясе эшендә

катнашучы затларга утырышны үткәрү датасы, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

11.4. утырыш башланыр алдыннан Аттестация комиссиясенә аның аерым әгъзаларының утырышта катнаша алмавы турында хәбәр итә;

11.5. эксперт аттестациясе алуга дәгъва кылучы гражданны (алга таба – мөрәҗәгать итүче) квалификация имтиханын уздырганда Аттестация комиссиясе утырышына чакыра;

11.6. Аттестация комиссиясе беркетмәсен алып бара һәм рәсмиләштерә.

11. Дәүләт комитеты белгечләре Аттестация комиссиясе әгъзалары булып тора.

Аттестация комиссиясе әгъзалары:

11.1. Аттестация комиссиясе утырышларында алмашу хокукыннан башка катнашалар;

11.2. Аттестация комиссиясе компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр кертәләр;

11.3. Аттестация комиссиясе рәисе йөкләмәләрен үтиләр;

11.4. тиешле документлар һәм материаллар белән танышалар;

11.5. әлеге Нигезләмәдә каралган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыралар.

11. Карарлар кабул иткәндә Аттестация комиссиясенең барлык әгъзалары да тигез хокукка ия.

## 3 бүлек. Аттестация комиссиясе эшен оештыру

12. Аттестация комиссиясе эше Дәүләт комитеты боерыкларына нигезләнеп башкарыла.

13. Аттестация ике этапта үткәрелә:

аттестациянең беренче этабы гариза бирүченең Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләүнең әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән критерийларга (алга таба – экспертларны аттестацияләү критерийлары) туры килүен тикшерү рәвешендә, тапшырылган документларны һәм белешмәләрне тикшерү юлы белән үткәрелә;

аттестациянең икенче этабы квалификация имтиханы рәвешендә үткәрелә.

14. Аттестация комиссиясе:

а) документларны карый, аларда булган белешмәләрнең тулылыгын һәм дөреслеген, шулай ук гариза бирүченең экспертларны аттестацияләү критерийларына туры килүен тикшерә;

б) җитмәгән документларны гариза бирүчедән соратып ала, тапшырылган документларны рәсмиләштергәндә җибәрелгән хаталарны бетерүне таләп итә;

в) гариза бирүченең экспертизаның билгеләнгән өлкәсендә компетентлылыгын бәяли торган квалификация имтиханын үткәрә;

г) эксперт аттестациясен туктату өчен нигезләрне тикшерә.

15. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларны һәм әлеге Нигезләмәнең 18 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне тикшерү нәтиҗәләре буенча Аттестация комиссиясе карарларның берсен кабул итә:

1. гариза бирүчене квалификация имтиханына кертү турында;

2. гариза бирүчене аттестацияләүдән баш тарту турында.

16. Аттестацияләүдән баш тарту турында карар кабул итү критерийлары:

- тапшырылган документларның әлеге Нигезләмәнең 18 пункты таләпләренә туры килмәве;

- гариза бирүченең экспертларны аттестацияләүнең расланган критерийларына туры килмәве.

## 4 бүлек. Квалификация имтиханын үткәрү тәртибе

17. Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертлар аттестациясен алуга дәгъва кылучы гражданнар өчен квалификация имтиханын (алга таба – квалификация имтиханы) үткәргәндә Аттестация комиссиясе гариза бирүчеләрнең белемнәрен, күнекмәләрен һәм осталыкларын (һөнәри дәрәҗәсен) Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган экспертларны аттестацияләү критерийлары нигезендә бәяли.

18. Гариза бирүче Дәүләт комитетына әлеге Нигезләмәгә кушымтада каралган форма буенча аттестация турында гаризаны, шулай ук Дәүләт комитеты боерыгы белән расланган экспертларны аттестацияләү критерийларына туры килүен раслый торган документларның күчермәләрен тапшыра:

а) архив белеме, тарих, эш башкару өлкәсендә югары һөнәри белемне раслый торган документлар күчермәләрен, шулай ук (булган очракта) гыйльми дәрәҗәсен раслый торган документларның күчермәләрен, аттестатларның, таныклыкларның, дипломнарның, сертификатларның күчермәләрен;

б) йә кәгазьдә тиешенчә таныкланган, йә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза (эш бирүчедә булганда) куелган электрон документ рәвешендә соңгы эш урыны буенча хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләрне;

в) шәхесне раслаучы документлар күчермәләрен.

19. Аттестация турында гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар күчермәләре гариза бирүче тарафыннан Дәүләт комитетына турыдан-туры тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен (алга таба – «Интернет» челтәре) кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Бердәм портал) аша җибәрелә.

20. Гариза бирүче аттестация турында гаризаның расланган формасын үтәмәсә яисә әлеге Нигезләмәнең 18 пунктында каралган документларның күчермәләрен тапшырмаса, Дәүләт комитеты күрсәтелгән документлар һәм гаризалар кергән көннән алып биш эш көне эчендә аларны, карамыйча, тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ

рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен (алга таба – «Интернет» челтәре) кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (алга таба – Бердәм портал) аша гариза бирүчегә кире кайтара;

21. Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларны һәм белешмәләрне тикшерүне Аттестация комиссиясе секретаре аттестация турында гариза кергән көннән алып 15 эш көненнән дә артмаган срокта башкара. Тикшерү нәтиҗәсе Аттестация комиссиясе рәисенә һәм әгъзаларына җиткерелә.

22. Аттестация комиссиясе секретаре гариза бирүчегә Аттестация комиссиясенең әлеге Нигезләмәнең 15 пунктында күрсәтелгән кабул ителгән карары турында мондый карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәрен кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән Бердәм портал аша хәбәр итә.

23. Квалификация имтиханын үткәрү датасы аттестация турында гариза алган көннән алып өч айдан да соңга калмыйча билгеләнә.

24. Аттестация комиссиясе секретаре, тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәрен кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән Бердәм портал аша, билгеләнгән датага кадәр 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә квалификация имтиханын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында хәбәрнамә юллый. Гариза бирүче квалификация имтиханын үткәрү урыны, датасы һәм вакыты турында хәбәрнамә Дәүләт комитеты тарафыннан җибәрелгән көннән соң 10 эш көне эчендә Дәүләт комитетына квалификация имтиханын үткәрү датасы һәм вакыты үзгәртү турында гариза җибәрергә хокуклы, ләкин аны аттестацияләү процедурасы кысаларында иң күбе бер тапкыр.

25. Бер үк вакытта квалификация имтиханын үткәрү өчен экспертиза төренә ярашлы рәвештә сораулар исемлеге (алга таба – сораулар исемлеге) төзелә һәм танышу өчен җибәрелә.

26. Сораулар исемлеге Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

27. Сораулар исемлегенә түбәндәгеләр керә:

- тест уздыру өчен сораулар (20);

- телдән сөйләшү өчен сораулар (20).

28. Квалификация имтиханы тест һәм телдән әңгәмә рәвешендә Аттестация комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

29. Гариза бирүче билгеләнгән вакытта квалификация имтиханына килергә тиеш, үзе белән шәхесен раслаучы документны булырга тиеш.

30. Квалификация имтиханы үткәрелә торган бүлмәдә бары тик гариза бирүче һәм Аттестация комиссиясе әгъзалары гына була ала.

31. Гариза бирүчегә тест уздыру өчен 20 сорауны үз эченә алган контроль имтихан эше булдырыла. Контроль имтихан эшләре экспертизаның билгеләнгән

төрепә ярашлы итеп һәм вариантлар исәбе гариза бирүчеләрнең санына тигез итеп төзелә.

32. Контроль имтихан эшен башкару өчен гариза бирүчегә 40 минут бирелә.

33. Квалификация имтиханын уздыру барышында гариза бирүчегә Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларыннан, белешмә, махсус һәм башка әдәбияттан, язмалардан, мобиль элемтә чараларыннан һәм мәгълүматны саклау һәм тапшыруның башка чараларыннан файдалану тыела.

Әлеге пунктта санап үтелгән тыюларны бозган очракта, гариза бирүче имтиханнан чыгарыла, тиешле язма Аттестация комиссиясе беркетмәсенә кертелә. Бу очракта гариза бирүче квалификация имтиханын тапшырмаган дип санала.

34. Башкарылган контроль имтихан эшен гариза бирүче Аттестация комиссиясе секретаренә тикшерү өчен тапшыра.

35. Контроль имтихан эшенең үтәлешен тикшергәннән соң гариза бирүче Аттестация комиссиясе әгъзалары белән телдән әңгәмә уздыру өчен чакырыла.

36. Телдән әңгәмә барышында Аттестация комиссиясе әгъзалары гариза бирүчегә аңа җибәрелгән сораулар исемлегендәге биш сорауга җавап бирергә тәкъдим итә.

37. Аттестация үткәрү нәтиҗәләре буенча карар гариза бирүче булмаганда Аттестация комиссиясе тарафыннан чыгарыла һәм, ачык тавыш биреп, утырышта катнашучы әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә.

38. Аттестация комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре Аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) белән рәсмиләштерелә.

39. Беркетмәгә Аттестация комиссиясе рәисе, секретаре һәм әгъзалары кул куя.

40. Беркетмәгә Аттестация комиссиясенә кергән барлык документлар кушып куела.

41. Аттестация комиссиясе утырышы беркетмәсенә нигезләнеп, Дәүләт комитеты квалификация имтиханы үткәрелгәннән соң өч эш көненнән дә артмаган срокта түбәндәге боерык чыгара:

а) әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча экспертларны аттестацияләү критерийларына туры килү турында карар кабул ителсә, гариза бирүчене аттестацияләү турында;

б) әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча экспертларны аттестацияләү критерийларына туры килмәү турында карар кабул ителгән булса йә гариза бирүче квалификация имтиханына килмәсә, гариза бирүчене аттестацияләүдән баш тарту турында.

42. Аттестацияләнү (аттестацияләүдән баш тарту) турында боерыкның күчермәсе боерык чыккан көннән алып өч эш көне эчендә гариза бирүчегә тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәрен кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән Бердәм портал аша җибәрелә (тапшырыла).

43. Аттестация турында боерык кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә Дәүләт комитеты экспертны аттестацияләү турында белешмәне Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору

буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителүче аттестацияләнгән экспертлар реестрына кертә, аны төзү һәм алып бару кагыйдәләре Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

44. Гариза бирүче Дәүләт комитетының һәм аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә, шулай ук судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

## 5 бүлек. Яңадан аттестацияләү тәртибе

45. Экспертлар әлеге Нигезләмәнең 4 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә һәр биш ел саен яңадан аттестацияләнергә тиеш.

46. Яңадан аттестацияләнергә тиешле эксперт гаризасы, аңа кушып бирелә торган документларның күчермәләре белән бергә, аттестация срогы чыкканга иң күбе 30 эш көне кала Аттестация комиссиясенә җибәрелә.

47. Аттестация комиссиясе беркетмә нигезендә түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча экспертларны аттестацияләү критерийларына туры килү турында карар кабул ителгән булса, экспертны яңадан аттестацияләү турында;

б) әгәр квалификация имтиханы нәтиҗәләре буенча экспертларны аттестацияләү критерийларына туры килмәү турында карар кабул ителгән булса яисә эксперт квалификация имтиханына килмәсә, экспертны яңадан аттестацияләүдән баш тарту турында,

48. Әлеге Нигезләмәнең 47 пунктындагы а) пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгәндә, экспертны яңадан аттестацияләү турында Дәүләт комитеты боерыгы чыгарыла. Аттестация комиссиясе экспертка тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәрен кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән Бердәм портал аша боерык күчермәсен җибәрә (тапшыра). Экспертны аттестацияләү биш елдан да артмаган вакытка озайтыла.

49. Яңадан аттестацияләүдән баш тарткан очракта Аттестация комиссиясе экспертка тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәрен кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән Бердәм портал аша экспертны яңадан аттестацияләүдән баш тарту турындагы боерык күчермәсен җибәрә (тапшыра).

50. Яңадан аттестацияләү турында боерык кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә Дәүләт комитеты Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителүче аттестацияләнгән экспертлар реестрына белешмәләр кертә, аны булдыру һәм алып бару кагыйдәләре Дәүләт комитеты боерыгы белән раслана.

51. Үзгәреләр булганда, шул исәптән экспертиза өлкәсе киңәйтелгән очракта, экспертлар әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнергә тиеш.

## 6 бүлек. Эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату тәртибе

52. Эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турында карар Дәүләт комитеты тарафыннан түбәндәгеләрдән алып өч эш көне эчендә кабул ителә:

1) Аттестация комиссиясенә аттестацияне туктату турында эксперт гаризасы кергәннән алып, ул ирекле рәвештә языла һәм тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәрен кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән Бердәм портал аша җибәрелә;

2) эксперт эшчәнлеге нәтиҗәләренең дөрес яисә объектив булмавы Дәүләт комитеты тарафыннан расланганнан алып;

3) экспертның әлеге Нигезләмәнең 5 бүлегендә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда яңадан аттестацияләү узмавыннан алып;

4) Дәүләт комитетына эксперт үлеме турында белешмәләр кергәннән алып.

53. Эксперт аттестациясенең гамәлдә булуын туктату турында боерык күчермәсе карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә тапшыру турында хәбәр ителә торган заказлы почта хаты белән йә гади электрон имза куелган электрон документ рәвешендә, «Интернет» челтәрен кертеп, һәркем өчен ачык мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, шул исәптән Бердәм портал аша экспертка җибәрелә (тапшырыла) (әлеге Нигезләмәнең 51 пунктындагы 4 пунктчасында каралган очрактан тыш).

54. Дәүләт комитеты тарафыннан әлеге Нигезләмәнең 51 пунктындагы 2, 3 пунктчаларында каралган нигезләр буенча аттестациянен гамәлдә булуын туктату турында карар кабул ителгән эксперт, мондый карар кабул ителгән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча, аттестацияләү турында гариза бирергә хокуклы.

Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү буенча Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты аттестация комиссиясе турында нигезләмәгә
кушымта

Татарстан Республикасының Архив
эше буенча дәүләт комитеты рәисе
Г. З. Габдрахмановага

________________________________________

________________________________________

(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

________________________________________

________________________________________

(яшәү урынының адресы)

________________________________________

________________________________________

________________________________________

(шәхесне раслаучы документ, ИНН)

________________________________________

(телефон номеры)

________________________________________

(электрон почта адресы)

Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче эксперт аттестациясенә дәгъва кылучы гражданны аттестацияләү турында
гариза

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия

Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшереп тору чараларын үткәрүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче эксперт итеп түбәндәге экспертиза төре буенча аттестацияләүне сорыйм:

- тикшерү объекты эшчәнлегенә архив документларының сакланышын оештыру буенча экспертиза
- тикшерү объекты эшчәнлегенә оешма архивының архив документларын туплауны оештыру буенча экспертиза
- объект эшчәнлегенә архив документларын исәпкә алуны оештыру буенча экспертиза
- тикшерү объекты эшчәнлегенә архив документларыннан файдалануны оештыру буенча экспертиза

Шулай ук мин, ________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
шәхси мәгълүматларның һәркем өчен ачык булган чыганакларын булдыру өчен мәгълүмат белән тәэмин итүнең иҗтимагый чыганакларын булдыру максатларында Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетына, минем шәхси мәгълүматларымны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (нигезләү, үзгәртү), тарату (шул исәптән тапшыру) һәм юкка чыгару гамәлләрен дә кертеп, минем шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә ризалык бирәм.

Гаризага кушымта итеп түбәндәгеләр бирелә:

1. архив белеме, тарих, эш башкару өлкәсендә югары һөнәри белем алуны раслый торган документлар күчермәләре, шулай ук гыйльми дәрәҗәне раслый торган документларның күчермәләре, аттестатларның, таныклыкларның, дипломнарның, сертификатларның күчермәләре, ________ бит 1 нөсхәдә;

2. хезмәт кенәгәсенең тиешле рәвештә расланган күчермәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турында Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 66[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә алынган белешмәләр, ___________ бит 1 нөсхәдә;

3. шәхесне раслаучы документлар күчермәләре.

| | | |
|---|---|---|
| ______________ | ______________ | __________________________ |
| (дата) | (имза) | (имзаның аңлатмасы) |

Татарстан Республикасы Архив
эше буенча дәүләт комитетының
«____» ________ ______
номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү критерийлары**

1.Аттестациянең әлеге критерийлары аттестацияләнгән булыр өчен гариза бирүче экспертизаның билгеле бер өлкәсендә җавап бирергә тиешле таләпләр җыелмасын билгели.

2. Эксперт аттестациясенең төп критерийлары түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

а) «Тарих – архив белеме», «Документлар белеме һәм документлар белән тәэмин итү», «Тарих» белгечлекләре буенча югары һөнәри белеме булу;

б) аттестацияләнә торган белгечлек буенча эш стажы кимендә 5 ел булу;

1) белү:

- «Россия Федерациясендә архив эше турында « 2004 елның 22 октябрендәге 125-ФЗ номерлы Федераль законны,

- «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елнын 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законны,

- «Татарстан Республикасы архив эше турында» 2017 елнын 20 июлендәге 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын,

- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының»Татарстан Республикасының Архив эше буенча Дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2016 елның 9 августындагы 541 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәне,

- Росархивның «Дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында эш башкару кагыйдәләрен раслау турында» 2019 елның 22 маендагы 71 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт органнарында, жирле үзидарә органнарында эш башкару кагыйдәләрен,

- Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Оешмаларның фәнни-техник һәм житештерү эшчәнлегендә барлыкка килә торган типлаштырылган архив документлары исемлеген раслау турында» 2007 елның 31 июлендәге 1182 номерлы боерыгы белән расланган Оешмаларның фәнни-техник һәм житештерү эшчәнлегендә барлыкка килә торган типлаштырылган архив документлары исемлеген, оешмаларның фәнни-техник һәм житештерү эшчәнлегендә барлыкка килә торган типик архив документларының саклау сроклары күрсәтелгән исемлеген,

- Росархивның «Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган типлаштырылган идарә итү архив

документларынын аларны саклау сроклары күрсәтелгән исемлеген раслау турында» 2019 елның 20 декабрендәге 236 номерлы боерыгы белән расланган Дәүләт органнары, жирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеге процессында барлыкка килә торган типлаштырылган идарә итү архив документларының аларны саклау сроклары күрсәтелгән исемлеген,

- Росархивның «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, фәнни оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм куллануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 2 мартындагы 24 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, фәнни оешмаларда башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм куллануны оештыру кагыйдәләрен,

- Россия Федерациясе Мәдәният һәм массакүләм коммуникацияләр министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт һәм муниципаль архивларда, музейларда һәм китапханәләрдә, Россия фәннәр академиясе оешмаларында башка архив документларын саклауны, туплауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру буенча исәпкә алу һәм башка документлар формаларын раслау турында» 2007 елның 10 сентябрендәге 1273 номерлы боерыгын,

- Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт хакимияте органнарында, жирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда башка архив документларын саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2015 елның 31 мартындагы 526 номерлы боерыгы белән расланган Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм дәүләт хакимияте органнарында, жирле үзидарә органнарында һәм оешмаларда башка архив документларын саклауны, комплектлауны, исәпкә алуны һәм файдалануны оештыру кагыйдәләрен,

- Россия Федерациясе Архив фонды документларын һәм башка архив документларын аларның милек рәвешенә бәйсез рәвештә саклау, туплау, исәпкә алу һәм файдалану өлкәсендә мөнәсәбәтләрне жайга сала торган башка Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын;

г) түбәндәгеләр буенча күнекмәләр булу:

- тикшереп тору чараларын үткәрү өчен кирәкле мәгълүматны эзләү, жыю, анализлау һәм системалаштыру;
- эшлекле хат язышу;
- компьютер һәм башка оргтехника белән эшләү;
- заманча мәгълүмат-коммуникация технологияләреннән файдалану;
- экспертизаны техник (технологик) чаралар кулланып үткәрү (кирәк булганда);

д) түбәндәге махсус һөнәри күнекмәләргә ия булу:

- архив эше өлкәсендә мөнәсәбәтләрне регламентлаштыра торган нормаларны үз эченә алган норматив хокукый актлар һәм локаль норматив актлар белән эшләү;
- хезмәт мәгълүматы белән эшләү;

- шәхси мәгълүматлар белән эшләү;
- белешмә-хокукый мәгълүмат системалары белән эшләү;
- тикшереп тору (күзәтчелек) чараларын гамәлгә ашыру барышында алынган мәгълүматка һәм документларга Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының архив эше турындагы законнары таләпләренә туры килү-килмәүгә экспертиза ясау;
- тикшерү предметы буенча йомгаклар чыгару һәм нигезләү;
- эксперт бәяләмәләрен төзү һәм рәсмиләштерү.

Татарстан Республикасының Архив
эше буенча дәүләт комитетының
«20» 07.2020, 113-од
номерлы боерыгы белән
расланды

**Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәргәндә кирәкле экспертизалар төрләре исемлеге**

1. Архив документларының сакланышын оештыру буенча тикшерү объекты эшчәнлегенә экспертиза.
2. Оешма архивының архив документларын туплауны оештыру буенча тикшерү объекты эшчәнлегенә экспертиза.
3. Архив документларын исәпкә алуны оештыру буенча объект эшчәнлегенә экспертиза.
4. Архив документларыннан файдалануны оештыру буенча тикшерү объекты эшчәнлегенә экспертиза.

Татарстан Республикасы Архив эше буенча дәүләт комитетының «20» 07.2020, 143-од номерлы боерыгы белән расланды

**Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә җәлеп ителүче аттестацияләнгән экспертлар реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре**

1. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшереп тору чараларын үткәрүгә дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан җәлеп ителүче экспертларны аттестацияләү турында» 2014 елның 10 июлендәге 636 номерлы карары нигезендә әлеге Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә җәлеп ителүче экспертлар реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә җәлеп ителүче экспертлар реестрын (алга таба – экспертлар реестры) булдыру һәм алып бару тәртибен билгели.

2. Экспертлар реестры экспертларны Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору буенча чаралар үткәрүгә Дәүләт комитеты тарафыннан җәлеп итү максатларында аларны исәпкә алу өчен төзелә һәм алып барыла.

3. Экспертлар реестрын булдыру һәм алып бару дәүләт комитетының Дәүләт контроле секторы тарафыннан башкарыла.

4. Экспертлар реестрына белешмәләр кертү, Дәүләт комитетының аттестация турындагы боерыгы нигезләнеп, аны кабул иткән көннән алып 3 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

5. Экспертлар реестрын булдыру һәм алып бару әлеге Кагыйдәләргә Кушымтада каралган форма буенча кәгазьдә һәм электрон рәвештә алып барыла.

6. Экспертлар реестрында аттестацияләнгән экспертлар турында танышу өчен ачык рәвештә түбәндәге белешмәләр бар:

6.1. эксперт турында түбәндәге мәгълүмат:

- фамилиясе, исеме, атасының исеме;

6.2. Аттестация турында түбәндәге белешмәләр:

- экспертны аттестацияләү турында боерыкның датасы һәм номеры;
- экспертиза төре;
- аттестация турында боерыкның датасы һәм номеры;
- эксперт эшчәнлеген туктату турында боерыкнын датасы һәм номеры.

7. Хезмәттә файдалану өчен түбәндәге өстәмә белешмәләр (кәгазьдә генә кертелә):

- төп эш урыны;

- төп эш урыны буенча вазыйфа;
- белем;
- шәхесне раслый торган документ;
- яшәү / теркәлү адресы;
- телефон номеры һәм электрон почта адресы.

8. Экспертлар реестрындагы белешмәләр, Россия Федерациясе законнары нигезендә файдалану чикләнгән мәгълүматка караган белешмәләрдән тыш, дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик һәм физик затлар тарафыннан танышу өчен ачык булып тора.

9. Экспертлар реестрындагы белешмәләр, Россия Федерациясе законнары нигезендә тарату чикләнгән яисә тыелган мәгълүматтан тыш, физик һәм юридик затлар гаризалары буенча гариза алынган көннән алып 30 көн эчендә реестрдан өземтә рәвешендә бирелә.

10. Реестрдагы белешмәләр түләүсез бирелә.

11. Экспертлар реестры Дәүләт комитетының рәсми сайтына урнаштырыла.

Татарстан Республикасында архив эше турындагы законнарның үтәлешен тикшереп тору чараларын үткәрүгә җәлеп ителүче аттестацияләнгән экспертлар реестрын булдыру һәм алып бару кагыйдәләренә
кушымта

| № т/б | экспертның ФИАи | Экспертны аттестацияләү турында боерыкның датасы һәм номеры | Экспертиза төре | Яңадан аттестацияләү турында боерыкның датасы һәм номеры | Эксперт эшчәнлеген туктату турында боерыкның датасы һәм номеры | Экспертның төп эш урыны | Экспертның төп эш урыны буенча вазыйфасы | Белем | Шәхесне таныклый торган документ | Яшәү урыны адресы | Телефон номеры һәм электрон почта адресы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |